**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» апрель 2020 ел № 120

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеш кодексының 31 статьясына ,2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41 карарлар редакциясендә) карары белән расланган , Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, А.Вәлиханов урамы, 5А йорт адресы буенча урнашкан, 16:44:01028:167 кадастр номерлы, 1158 кв.м. мәйданлы җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге Д1-шәхси торак йортлар төзү зонасына үзгәртергә.

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Әлмәт тракты, 20В йорт адресы буенча урнашкан 957 кв.м мәйданлы 16:44:0000:487 кадастр номерлы жир кишәрлеге өчен, П4 куркынычлыгының V класслы җитештерү-коммуналь объектлары зонасыннан, Ж1 шәхси торак йортлар төзү зонасына П4 куркынычлылык зонасыннан территориаль зонаны үзгәртергә.

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручы- Азнакай шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;

- ачык тыңлауларны уткәру вакыты-2020 елның 9 апреленнән 12 майга -17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны: ТР – Азнакай ш., Ленин ур., 14;

– язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертә ала торган адрес- ТР, Азнакай ш., м. Солтангалиев ур., 24 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге (эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр).

3. Азнакай шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы закон проекты буенча нигезендә ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

-Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарны "Татарстан http://pravo.tatarstan.ruРеспубликасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М. З. Шәйдуллин